# 1нче САНЛЫ ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

06 декабрь 2021 ел

Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында”, 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында”, 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законының 35 статьясы нигезендә, 2021 елның 03 декабрендә 11 сәгать 00 минутта, 2021 елның 03 декабрендә 14 сәгать 00 минутта, 2021 елның 03 декабрендә 16 сәгать 00 минутта уздырылган “Сез 2022 елда Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ авылы территориясендә даими яшәүче һәм яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм җыелган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияткә ия мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерү белән килешәсезме?” дигән мәсьәлә буенча этаплап гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:

1)Ямаширмә авылында ял паркын төзекләндерү (балалар мәйданчыгы элементларын, урам тренажерлары, яктырткычлар сатып алу);

2)Ямаширмә авылы эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу һәм җәю, юлларны кышкы карап тоту: трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту);

3)Ямаширмә авылын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм карап тоту (торбалар сатып алу һәм салу);

4) янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүченең хезмәт хакы).

«РИЗА» «КАРШЫ».

Гражданнар җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә гражданнар җыенында катнашучы 809 (сигез йөз тугыз) кеше кертелгән, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар саны 420 (дурт йөз егерме) кеше, бу 52%ны тәшкил итә.

тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар түбәндәгечә бүленде:

“Риза” позициясе өчен гражданнар җыенында 420 (дурт йөз егерме) катнашучы тавыш бирде; “Каршы” позициясе өчен җыенда катнашучы 0 (ноль) кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, гражданнар җыены түбәндәгечә хәл итте:

1. Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмэ авыл җирлеге Ямаширмэ торак пунктында гражданнар җыенын узган дип, гражданнар җыены нәтиҗәләрен дөрес дип таныйрга.

2. 2022 елда үзара салым акчасын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Ямаширмә авыл җирлеге территориясендә даими яшәүче балигъ булган һәр кешедән 500 сум (биш йөз) күләмендә кертергә.

3. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1)Ямаширмә авылында ял паркын төзекләндерү (балалар мәйданчыгы элементларын, урам тренажерлары, яктырткычлар сатып алу);

2)Ямаширмә авылы эчендәге юлларны ремонтлау һәм карап тоту (вак таш сатып алу һәм җәю, юлларны кышкы карап тоту: трактор өчен ягулык-майлау материаллары сатып алу, кар чистарту);

3)Ямаширмә авылын су белән тәэмин итү системасын ремонтлау һәм карап тоту (торбалар сатып алу һәм салу);

4) янгын сүндерү машинасын ремонтлау һәм карап тоту (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, машина йөртүченең хезмәт хакы).а) Ямаширмә авылында ял паркын төзекләндерү (җиһазлар сатып алу һәм урнаштыру, материаллар сатып алу һәм юл өслеге урнаштыру, яшелләндерү);

4. Әлеге карарны Биектау муниципаль районы рәсми сайтында Интернет челтәрендә http://vysokaya-gora.tatarstan.ru веб-адресы һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында “Интернет” мәгълүмат-телекоммуникацияләр челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлар регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында рәислек итүче Ф.К.Мухтаров